**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясен бирү комитеты составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 4 июнендәге ПУ-503 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-460 номерлы, 2018 елның 27 гыйнварындагы ПУ-109 номерлы, 2018 елның 17 ноябрендәге ПУ-778 номерлы, 2020 елның 21 июлендәге ПУ-432 номерлы, 2020 елның 25 ноябрендәге ПУ-778 номерлы, 2021 елның 21 июнендәге ПУ-503 номерлы, 2022 елның 8 июлендәге ПУ-470 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 19 июнендәге 412 номерлы, 2024 елның 8 июлендәге 522 номерлы һәм 2024 елның 7 августындагы 611 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комитет составына Дамар Диларә Фикърәт кызын – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе каршындагы Татарстан халыклары Яшьләр ассамблеясе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы рәисен (килешү буенча) кертергә;

б) Комитет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.И. Бикеевның – «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесенең беренче проректоры, фәнни эш буенча проректоры (килешү буенча)»;

Р.Н. Вәлиуллинның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча)»;

Т.Р. Кадыйровның – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары, «Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, Комитет рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

Т.Г. Какохоның – «Россия юристлар ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе Башкарма комитеты рәисе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының хокук мәсьәләләре һәм иҗтимагый контроль комиссиясе рәисе (килешү буенча)»;

Д.Ф. Шакировның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисенең беренче урынбасары – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ ГОМУМИ БҮЛЕК
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 27 июнь
№ 506